## ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы
Бикбау авыл җирлегенең Бикбау торак пунктында
2025 елдагражданнарның үзара салым кертү турында

**20 ноябрь 2024 ел** **№ 1**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 елгы №131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 елгы №45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә,Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Бикбау авыл җирлегенең Бикбау торак пунктында гражданнар җыены

**КАРАР ЧЫГАРА:**

«Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районының Бикбау авыл җирлеге Бикбау торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 2025 елда 1000 сум күләмендә үзара салым кертергә,1 һәм 2 төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышы һәм сугышчан хәрәкәтләр ветераннарыннан, Бөек Ватан сугышында һәм сугышчан хәрәкәтләрдә катнашучыларның тол хатыннарыннан, күпбалалы гаиләләрдән, көндезге формада укучы студентлардан, Россия Армиясе сафларына хезмәткә чакырылган гражданнардан, мобилизацияләнгәннәрдән һәм аларның гаилә әгъзаларыннан тыш.

2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

1) Бикбау торак пунктында тышкы яктырту урам челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җайланмаларны ремонтлау(урам яктырту лампочкаларын 15 данә алмаштыру, шартнамә буенча хезмәт күрсәтүләр өчен түләү);

2) Бикбау торак пункты территориясен төзекләндерү (паркта стендлар рәсмиләштерү һәм урнаштыру (шартнамә буенча хезмәт күрсәтүләр өчен түләү);

3) Бикбау торак пунктында су белән тәэмин итү һәм су түгү системаларын, су җыю манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортировкалауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итүче башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау (паркка суүткәргеч линиясен үткәрү, хезмәт күрсәтүләр өчен шартнамә буенча түләү);

4) Бикбау торак пункты территориясен төзекләндерү (юл кырыен һәм аның тирәсендәге территорияне чабу, шартнамә буенча хезмәт күрсәтүләр өчен түләү)

3.Әлеге карарны Бикбау авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә, Минзәлә муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга (http:// menzelinsk.tatarstan.ru), рәсми хокукый мәгълүмат сайтында (http://pravo.tatarstan.ru) кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә.

Халык җыенында рәислек итүче,
Минзәлә муниципаль районы
Бикбау авыл җирлеге башлыгы — Л. Н. Мәрдәмшина